СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

_______________ с. Татарское Бурнашево _______________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

"Коррупциягә каршы көрәш турында" 25.12.2008 елгы 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау хакында" Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Советының 07.03.2023 ел № 28-159 карары;

Югары Ослан муниципаль районы авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Бурнаш авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәл булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чаралары күрү тәртибен раслау хакында" Борнаш авыл җирлеге Советының 2020 елның 16 июнендәге 76-350 номерлы карары;

Югары Ослан муниципаль районы авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында" Борнаш авыл җирлеге Советының 07.03.2023 елның 28-157 номерлы карары;

«Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау һәм массакүләм мәгълүмат чараларына «Борнаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» Югары Ослан муниципаль районы Советының 25.10.2017 елның 31-141 номерлы карары.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин